Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2025 Менделеевск ш. № 242

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы территориясендәге
торак урынны торак булмаган урынга һәм
торак булмаган урынны торак урынга күчерү
буенча комиссия составын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендәге торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү буенча комиссия составын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 гыйнварендагы 22 номерлы, 2022 елның 18 маендагы 344 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2025 елның
2 апрелендәге 242 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендәге торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Рәис: | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары; |
| Рәис урынбасары: | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы; |
| Секретарь: | - Татарстан Республикасы " Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең рөхсәт документациясе бүлеге баш белгече; |
| Комиссия әгъзалары: | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;<br>- Татарстан Республикасы " Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;<br>- Татарстан Республикасы " Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы;<br>- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен үстерү бүлеге башлыгы; |

- Менделеевск район эксплуатация-газ хезмәте башлыгы (килешү буенча).